КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 20 ноябрь г.Казань № 1023

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 9 март, 132 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 9 март, 132 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 13 июнь, 379 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем, шәхси гомуми белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми,

төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия түбәндәге таләпләргә җавап бирә торган шәхси белем бирү оешмаларына, шәхси эшмәкәрләргә бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген алып барган;

мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген алып барырга тиешле лицензияләре булган;

башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт аккредитациясен алган;

субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырылган айга кадәр булган айның беренче көненә:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаган;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) кире кайтару буенча һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка үз вакытында түләмәгән бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмаган, ә субсидия алучылар – шәхси эшмәкәрләр үз эшчәнлеген шәхси эшмәкәр сыйфатында туктатмаган;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 процентган артып киткән россия юридик затлары булмаган;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджетыннан акча алмаган;

«Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасында мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмалары реестрына кертелгән (мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр өчен).»;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алу өчен шәхси белем бирү оешмалары, шәхси эшмәкәрләр Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча субсидия бирү турында гариза;

шәхси белем бирү оешмасы җитәкчесенең яки ул вәкаләтләр биргән затның вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсен, шәхси эшмәкәрнең шәхесен таныклый торган документ күчермәсен;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләрен;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган документларны;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) кире кайтару буенча һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка үз вакытында түләмәгән бурычлары булмавын раслый торган документларны;

шәхси белем бирү оешмасының үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмавын, ә субсидия алучылар – шәхси эшмәкәрләр үз эшчәнлеген шәхси эшмәкәр сыйфатында туктатмавын раслый торган документларны;

шәхси белем бирү оешмасының, шәхси эшмәкәрнең бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджетыннан акча алмавын раслый торган документларны;

штат расписаниесе күчермәсен;

укучыларны кабул итү турында боерыклар реквизитларын, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамәләр реквизитларын күрсәтеп, сыйныфлар буенча гариза бирү көнендә башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча төп белем бирү программаларын тормышка ашыручы шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә укучылар исемлеген;

тәрбияләнүчеләрне кабул итү турында боерыклар реквизитларын, ата-аналар (законлы вәкилләр) белән шартнамәләр реквизитларын күрсәтеп, төркемнәр буенча гариза бирү көнендә «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программаларын тормышка ашыручы шәхси белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрләрдә тәрбияләнүчеләр исемлеген;

субсидия зурлыгын исәпләү өчен төркемнәр (сыйныфлар) саны, укучылар (тәрбияләнүчеләр) саны турында, белем бирү программалары, территориаль урнашуы, эш режимы, гомуми белем бирү дәрәҗәсе хакында Министрлык билгеләгән форма буенча мәгълүмат;

гариза бирү көненә кадәр килүче соңгы хисап чоры өчен «Хезмәткәрләр саны һәм эш хакы турында мәгълүматлар» дигән П-4 номерлы федераль статистик күзәтү формасының Дәүләт статистикасы федераль хезмәте территориаль органының аны кабул итү турында тамгасы булган күчермәсен (юридик затлар өчен).»;

8 нче пунктның дүртенче абзацына «яки Юридик затларның (шәхси эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестрыннан язу битен (шәхси эшмәкәрләр өчен)» сүзләрен өстәргә;

17 нче пунктның өченче абзацында «шулай ук бу Тәртип белән билгеләнгән субсидия бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш» сүзләрен төшереп калдырырга;

18 нче пунктта:

1 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия күләмен исәпләү өчен ике айдан өч яшькә кадәр төрле яшьтәге төркемнәр, өч яшьтән җиде яшькә кадәр өч яшьтәге төркемнәр өчен һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы бары шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә тиешле яшьтәге (ике айдан өч яшькә кадәр, өч яшьтән җиде яшькә кадәр) бер төркем буенча эшләгәндә генә кулланыла. Әгәр дә шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә тиешле яшьләрдәге (ике айдан өч яшькә кадәр, өч яшьтән җиде яшькә кадәр) 1 дән артыграк төркем эшләсә, субсидия күләмен исәпләү өчен бер яшьтәге төркемнәр өчен өчен һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы кулланыла;»;

2 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия күләмен исәпләү өчен ике айдан өч яшькә кадәр төрле яшьтәге төркемнәр, өч яшьтән җиде яшькә кадәр өч яшьтәге төркемнәр өчен һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы бары шәхси гомуми белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә тиешле яшьтәге (ике айдан өч яшькә кадәр, өч яшьтән җиде яшькә кадәр) бер төркем буенча эшләгәндә генә кулланыла. Әгәр дә шәхси гомуми белем бирү оешмасында, шәхси эшмәкәрдә тиешле яшьләрдәге (ике айдан өч яшькә кадәр, өч яшьтән җиде яшькә кадәр) 1 дән артыграк төркем эшләсә, субсидия күләмен исәпләү өчен бер яшьтәге төркемнәр өчен өчен һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен финанслар белән тәэмин итү нормативы кулланыла.»;

20 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хисап бирү көненә кадәр килүче соңгы хисап чоры өчен «Хезмәткәрләр саны һәм эш хакы турында мәгълүматлар» дигән П-4 номерлы федераль статистик күзәтү формасының Дәүләт статистикасы федераль хезмәте территориаль органының аны кабул итү турында тамгасы булган күчермәсен (юридик затлар өчен).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин